КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 27 май г.Казань № 379

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының үзәк аппараты структурасы стандартын раслау турында» 2008 ел, 7 апрель, 207 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының үзәк аппараты структурасы стандартына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының үзәк аппараты структурасы стандартын раслау турында» 2008 ел, 7 апрель, 207 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 13 май, 313 нче; 2021 ел, 2 март, 109 нчы; 2021 ел, 1 апрель, 202 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының үзәк аппараты структурасы стандартына, 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3. Дәүләт хакимияте башкарма органының үзәк аппаратында (территориаль бүлекчәләрне исәпкә алмыйча):

дәүләт хакимияте башкарма органы җитәкчесе урынбасарлары, шулай ук структур бүлекчәләр җитәкчеләренең һәм аларның урынбасарлары саны дәүләт хакимияте башкарма органы үзәк аппараты хезмәткәрләренең гомуми штат санының 30 процентыннан артмаска тиеш;

төп киңәшчеләр саны дәүләт хакимияте башкарма органы үзәк аппараты хезмәткәрләренең гомуми штат санының 20 процентыннан артмаска тиеш;

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының өлкән һәм кече төркемнәренә кертелгән дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче хезмәткәрләрнең гомуми саны дәүләт хакимияте башкарма органы үзәк аппаратының гомуми штат санының кимендә 10 процентын тәшкил итәргә тиеш.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин